**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**

**Алькеевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Әлки муниципаль районы**

**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Адрес: 422870, РТ, с. Базарные Матаки, ул. Крайнова, 56
тел: 8 (84346) 2-17-60

Адресы: 422870, РТ, Базарлы Матак авылы, Крайнов ур., 56
факс: 8 (84346) 2-17-60

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2020 елның 12 мае** **192№**

Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 3 февралендәге «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә муниципаль мәгълүмат системаларының эшләве һәм алардан файдалану Тәртибен раслау турында»гы 32 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

2013 елның 5 апрелендәге «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында»гы 44-ФЗ номерлы Федераль закон, РФ Хөкүмәтенең 2019 елның 27 декабрендәге «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында»гы 1906 номерлы Карары, 2017 елның 31 декабрендәге «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында»гы 504-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында»гы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 3 февралендәге «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә муниципаль мәгълүмат системаларының эшләве һәм алардан файдалану тәртибен раслау турында» 32 номерлы карарына (2018 елның 14 декабрендәге 469 номерлы редакциядә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 4 пунктның 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) сатып алу план-графикларында (алга таба - план-графиклар), сатып алулар турындагы хәбәрнамәләрдә, тәэмин итүчеләрне (подрядчыларны, башкаручыларны) билгеләү беркетмәләрендә, контракт (әлеге Федераль закон нигезендә контрактлар төзелеп сатып алуларда катнашучыларга бердәм мәгълүмат системасын кулланып җибәреләүче)

проектлары шартларында булган сатып алуларның идентификацион кодлары турындагы мәгълүматның туры килүен һәм әлеге сатып алуларны гамәлгә ашыру өчен финанс ягыннан тәэмин итү күләмен арттырмауны контрольдә тоту;

- 4 пунктның 4 пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

- 9 пунктның б пунктчасында «сатып алу планнары һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Әлки муниципаль районының рәсми сайтында rehttp://alkeevskiy.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

**Җитәкче:** **И.В.Юсупов**